Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Инеш поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Молодежная урамында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2 декабрь 2024 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы нигезендә, 2024 елның 2 декабрендә 17 сәгать 30 минутта узган «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Инеш поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Молодежная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту эшләре башкару;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 217 (ике йөз унҗиде) катнашучы кертелгән, 110 (йөз ун) кеше гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан, бу 51 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 110 (йөз ун) катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Инеш поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Молодежная урамында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Инеш поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Молодежная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту эшләре башкару;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авыл җирлеге, Зур Кызыл урамы, 113 А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнашттыру юлы белән халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.А. Хабибуллин